ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылында
2026 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

2025 елның 18 ноябре №16

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пунктының Октябрь урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түбәндәге категория гражданнардан тыш, 2026 елда 6250 сум күләмендә үзара салым кертергә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
в) СВО катнашучылары гаиләләре

Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Шилангы авылының Октябрь урамы буенча торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл төзү);

Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров